КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 апрель г.Казань № 276

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы; 2017 ел, 21 март, 162 нче; 2017 ел, 13 июль, 490 нчы, 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче, 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре, республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү, дәүләт учреждениеләренең дәүләт йөкләмәләрен үтәвен мониторинглауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең гамәли көче «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә кагылмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин